СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**19.09.2017г.** **с.Ямбулатово** **№ 30 – 122**

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п. 1 пункты, Ямбулат авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Ямбулат авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләре буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2018 елда авыл җирлегенең җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешерсезме:

- Ямбулат авылы җирлегендә урнашкан Казыльяры, Крестниково, Ямбулат авылларындагы чишмәләрнең санитар зонасын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү;

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н. Әхмәтҗанов